КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 13 сентябрь г.Казань № 868

Олыларга яңа коронавирус йогышлы авыруына каршы вакцинация ясауны үткәрүдә катнашучы медицина хезмәткәрләренә өстәмә башкарыла торган эш өчен стимул бирү характерындагы түләүләрне финанслар белән тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен һәм әлеге стимул бирү характерындагы түләүләр бирелгән медицина хезмәткәрләренәяллар өчен түләүгә һәм файдаланылмаган яллар өчен компенсация түләүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү тәртибен һәм Олыларга яңа коронавирус йогышлы авыруына каршы вакцинация ясауны үткәрүдә катнашучы медицина хезмәткәрләренә өстәмә башкарыла торган эш өчен стимул бирү характерындагы түләүләрне бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Олыларга яңа коронавирус йогышлы авыруына каршы вакцинация ясауны үткәрүдә катнашучы медицина хезмәткәрләренә өстәмә башкарыла торган эш өчен стимул бирү характерындагы түләүләрне финанслар белән тәэмин итү буенча Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен һәм әлеге стимул бирү характерындагы түләүләр бирелгән медицина хезмәткәрләренә яллар өчен түләүгә һәм файдаланылмаган яллар өчен компенсация түләүгә бәйле чыгымнарны финанслашу максатларында, 2021 елда федераль бюджеттан Россия Федерациясе Хөкүмәте

резерв фондының бюджет ассигнованиеләре финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып торган Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына максатчан билгеләнештәге башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 23 августындагы 1396 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Олыларга яңа коронавирус йогышлы авыруына каршы вакцинация ясауны үткәрүдә катнашучы медицина хезмәткәрләренә өстәмә башкарыла торган эш өчен стимул бирү характерындагы түләүләрне финанслар белән тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен һәм әлеге стимул бирү характерындагы түләүләр бирелгән медицина хезмәткәрләренә яллар өчен түләүгә һәм файдаланылмаган яллар өчен компенсация түләүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү тәртибен;

Олыларга яңа коронавирус йогышлы авыруына каршы вакцинация ясауны үткәрүдә катнашучы медицина хезмәткәрләренә өстәмә башкарыла торган эш өчен стимул бирү характерындагы түләүләрне бирү тәртибен.

2. Бу карарның гамәле 2021 елның 27 августыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла һәм 2021 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була дип билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 13 сентябрь, 868 нче
карары белән расланды

Олыларга яңа коронавирус йогышлы авыруына каршы вакцинация ясауны үткәрүдә катнашучы медицина хезмәткәрләренә өстәмә башкарыла торган эш өчен стимул бирү характерындагы түләүләрне финанслар белән тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен һәм әлеге стимул бирү характерындагы түләүләр бирелгән медицина хезмәткәрләренә яллар өчен түләүгә һәм файдаланылмаган яллар өчен компенсация түләүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү
тәртибе

1. Бу Тәртип олыларга яңа коронавирус йогышлы авыруына каршы вакцинация ясауны үткәрүдә катнашучы медицина хезмәткәрләренә өстәмә башкарыла торган эш өчен стимул бирү характерындагы түләүләрне финанслар белән тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен һәм әлеге стимул бирү характерындагы түләүләр бирелгән медицина хезмәткәрләренә яллар өчен түләүгә һәм файдаланылмаган яллар өчен компенсация түләүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү механизмын билгели.

2. Олыларга яңа коронавирус йогышлы авыруына каршы вакцинация ясауны үткәрүдә катнашучы медицина хезмәткәрләренә өстәмә башкарыла торган эш өчен стимул бирү характерындагы түләүләрне финанслар белән тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен һәм әлеге стимул бирү характерындагы түләүләр бирелгән медицина хезмәткәрләренә яллар өчен түләүгә һәм файдаланылмаган яллар өчен компенсация түләүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджеты акчасы һәм әлеге чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансферт (алга таба – акча, стимул бирү характерындагы түләүләр) исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Акча яңа коронавирус йогышлы авыруына каршы вакцинация ясарга планлаштырыла торган халык булганда тотыла.

Акча Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомствосы буйсынуында булган, медицина хезмәткәрләре яңа коронавирус йогышлы авыруына каршы вакцинация ясауны үткәрүдә катнаша торган медицина оешмаларына җибәрелә.

3. Бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән чараларны тормышка ашыруга каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче булып Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тора.

4. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән чараларны тормышка ашыруга акча җибәрә.

5. Акчаны тоту Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгында ачылган шәхси счет аша башкарыла.

6. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы финанслауның иң чик күләмнәрен Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан финанслауның иң чик күләмнәрен җиткергәннән соң расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә җиткерә.

7. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән чараларны тормышка ашыру максатларында:

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясындагы 1 пунктының икенче абзацына таянып, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомствосы буйсынуындагы бюджет һәм автоном учреждениеләр булып торучы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмалары белән, иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең «Электрон бюджет» дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасыннан файдаланып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслаган бертип форма һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә бәйле булмаган башка максатларга субсидияләр бирү шартларын һәм күләмен билгеләү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 30 декабрь, 1052 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә бәйле булмаган башка максатларга субсидияләр бирү шартларын һәм күләмен билгеләү тәртибе нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турында килешүләр төзи;

Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия акчасын медицина оешмаларына күчерә.

Һәр медицина оешмасы өчен субсидия күләме ($S_i$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S_i = ((N_i \times (V_i + O_i)) \times 1{,}302),$$

монда:

$N_i$ – i-медицина оешмасы тарафыннан вакцинация ясалган халык саны, кеше;

$V_i$ – вакцинация ясаган бер кеше өчен медицина хезмәткәрләренә матди стимул бирүнең җыелма күләме (200 сум);

$O_i$ – вакцинация ясаган бер кеше өчен медицина хезмәткәрләренә матди стимул бирүгә каралган акча суммасы өлешендә ел саен бирелә торган ял өчен түләүгә һәм файдаланылмаган ял өчен компенсация түләүгә кирәкле акча суммасы;

1,302 – хезмәт өчен түләү буенча түләүләргә исәпләүләр күләмен чагылдыра торган коэффициент.

Вакцинация ясаган бер кеше өчен медицина хезмәткәрләренә матди стимул бирүгә каралган акча суммасы өлешендә ел саен бирелә торган ял өчен түләүгә һәм

файдаланылмаган ял өчен компенсация түләүгә кирәкле акча суммасы ($O_i$) түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$O_i = \sum\left(\left(\frac{V_i}{12} \times \frac{1}{29,3}\right) \times k_i\right),$$

монда:

$V_i$ – вакцинация ясаган бер кеше өчен медицина хезмәткәрләренә матди стимул бирүнең җыелма күләме (200 сум);

12 – медицина хезмәткәрләренә яллар өчен түләүгә һәм файдаланылмаган яллар өчен компенсация түләүгә бер көнлек уртача эш хакын Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Уртача эш хакын исәпләү тәртибе үзенчәлекләре турында» 2007 елның 24 декабрендәге 922 номерлы карары нигезендә исәпләү өчен кулланыла торган айлар саны;

29,3 – медицина хезмәткәрләренә яллар өчен түләүгә һәм файдаланылмаган яллар өчен компенсация түләүгә бер көнлек уртача эш хакын Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Уртача эш хакын исәпләү тәртибе үзенчәлекләре турында» 2007 елның 24 декабрендәге 922 номерлы карары нигезендә исәпләү өчен кулланыла торган календарь көннәрнең уртача айлар саны;

$k_i$ – зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартлары булган эш өчен ел саен бирелә торган өстәмә түләүле ялны исәпкә алып, i-медицина хезмәткәре ялының календарь көннәре саны.

8. Медицина оешмалары ай саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 2 сеннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнгән формалар буенча субсидия акчасыннан файдалану турында Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына хисаплар бирә.

9. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы бирелгән субсидия акчасын медицина оешмалары тарафыннан түбәндәге очракларда кире кайтаруны тәэмин итә:

субсидия акчасына ихтыяҗ булмаганда (кимегәндә);

медицина оешмалары тарафыннан дөрес булмаган хисаплылык бирелгәндә;

медицина оешмалары тарафыннан субсидия акчасы максатчан файдаланылмаганда.

10. Бу Тәртипнең 9 пунктында күрсәтелгән очракларда медицина оешмаларына бирелгән субсидия акчасы Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының тиешле таләбен алган көннән 15 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Медицина оешмалары тарафыннан субсидия акчасын кире кайтару сроклары бозылганда Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы бу пунктның беренче абзацында билгеләнгән срок тәмамланган көннән 30 көн эчендә субсидия акчасын Татарстан Республикасы бюджетына законнар белән билгеләнгән тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.

11. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы акчаны максатчан файдалануны тикшерүдә тотуны тәэмин итә.

12. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең «Электрон бюджет» дәүләт берләштерелгән мәгълүмат системасына Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында төзелгән Башка бюджетара трансферт бирү турындагы килешүдә билгеләнгән формада һәм срокларда финанслашу максаты белән башка бюджетара трансферт бирелә торган Россия Федерациясе субъекты бюджеты чыгымнары турында хисап һәм башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешү турында хисап урнаштыра.

13. Агымдагы финанс елының 1 гыйнварына башка бюджетара трансфертның файдаланылмый калган өлеше Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән таләпләр нигезендә федераль бюджетка кире кайтарылырга тиеш.

___

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 13 сентябрь, 868 нче
карары белән расланды

Олыларга яңа коронавирус йогышлы авыруына каршы вакцинация ясауны үткәрүдә катнашучы медицина хезмәткәрләренә өстәмә башкарыла торган эш өчен стимул бирү характерындагы түләүләрне бирү
тәртибе

Бу Тәртип Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомствосы буйсынуындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларының (алга таба – медицина оешмалары) олыларга яңа коронавирус йогышлы авыруына каршы вакцинация ясауны үткәрүдә катнашучы медицина хезмәткәрләренә өстәмә башкарыла торган эш өчен стимул бирү характерындагы түләүләрне (алга таба – стимул бирү характерындагы түләүләр) бирү максатын, механизмын һәм шартларын билгели.

2. Стимул бирү характерындагы түләүләр яңа коронавирус йогышлы авыруына каршы вакцинация ясауны үткәрүдә катнашучы медицина хезмәткәрләренә матди стимул бирү максатларында вакцинация ясаган бер кеше өчен тулаем 200 сум күләмендә билгеләнә.

Стимул бирү характерындагы түләүләрне исәпләү 2021 елның 27 августыннан 2021 елның 31 декабренә кадәр (31 декабрьне кертеп) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) таралуны бетерү максатларында мәгълүматны исәпкә алуның вакытлыча кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 31 мартындагы 373 номерлы карары белән Вакытлыча алып бару кагыйдәләре расланган яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) таралуны бетерү максатларында мәгълүматны исәпкә алуның мәгълүматлар ресурсына кертелгән физик затларга вакцинация ясаган өчен гамәлгә ашырыла.

3. Стимул бирү характерындагы түләүләр вакцинация ясаган бер кеше өчен түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

а) вакцинация ясауның беренче этабында (вакцинаның беренче компонентын ясауны оештырганда һәм керткәндә):

вакцинация ясау алдыннан пациентны карауны башкарган медицина хезмәткәрләренә – 60 сум;

вакцинация ясауны башкарган медицина хезмәткәрләренә – 40 сум;

б) вакцинация ясауның икенче этабында (вакцинаның икенче компонентын керткәндә):

вакцинация ясау алдыннан пациентны карауны башкарган медицина хезмәткәрләренә – 60 сум;

вакцинация ясауны башкарган медицина хезмәткәрләренә – 40 сум.

4. Медицина оешмалары, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән килештереп, локаль норматив акт белән түбәндәгеләрне билгели:

а) медицина хезмәткәрләре олыларга яңа коронавирус йогышлы авыруына каршы вакцинация ясауны үткәрүдә катнашучы медицина оешмаларының структур бүлекчәләре исемнәре исемлеген;

б) медицина оешмалары бүлекчеләренең олыларга яңа коронавирус йогышлы авыруына каршы вакцинация ясауны үткәрүдә катнашучы медицина хезмәткәрләре вазыйфалары исемлеген;

в) стимул бирү характерындагы түләү күләмен һәм стимул бирү характерындагы түләү билгеләнә торган срокны.

5. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы стимул бирү характерындагы түләүләрне гамәлгә ашыру өчен медицина оешмаларына Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан раслана торган формада буенча медицина оешмалары заявкалары нигезендә субсидияләр рәвешендә акча күчерә.

6. Медицина оешмалары стимул бирү характерындагы түләүләрне гамәлгә ашыруга билгеләнгән акчадан максатчан файдаланган өчен җавап бирә.

---